**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

14 декабрь 2024 ел　　　　　　　　　　　　　　　№ 250

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар итте:

1. 1 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта хупларга.

2. Муниципаль район Уставына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә Әтнә район Советы депутатларының һәм Әтнә районы прокуратурасының Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрен өйрәнү һәм гомумиләштерү эшен дәвам итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен (3 нче кушымта) расларга.

5. «Татарстан Республикасы «Әтнә муниципаль районы» берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча 2025 елның 17 гыйнварына 9.00 сәгатьтә Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының актлар залында гавами тыңлаулар билгеләргә.

6. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр эш төркеменә язма рәвештә, мөрәҗәгать авторының фамилиясен,

исемен, атасының исемен, туу датасын, яшәү урынын һәм контакт телефоннарын күрсәтеп, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша 2025 елның 15 гыйнварына кадәр җибәрелә дип билгеләргә.

7. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының www.pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов